**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Нижнекуюкское сельское поселение Атнинского муниципального района**
422741, с.Нижний Куюк, ул. Татарстан, д.71а
Тел./факс.: (8-84369) 33247

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге**
422741, Түбән Көек авылы, Татарстан урамы., 71а йорты
Тел./факс.: (8-84369) 33247

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» ноябрь 2025 ел. № 3

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Җәмәгать хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2025 елның 4 декабрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 4 декабрь 2025 ел 10.30 сәг.тән 11.30 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны — Яңа Шимбер авылы, Тукай урамы, 26 йорт янында;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Яңа Шимбер торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Яңа Шимбер торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Шимбер бистәсендә үлән чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ); (Яңа Шимбер авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));
2) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71а йортындагы мәгълумат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Д.М. Галиәхмәтов